КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 28 июнь г.Казань № 442

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасының дәүләт бюджеттан тыш фондлары белән идарә итү органнары һәм аларның территориаль органнары, ведомстволарындагы казна учреждениеләре функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләү кагыйдәләрен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, әлеге актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә таләпләрне раслау хакында» 2016 ел, 20 апрель, 242 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 4 өлешнең 2 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт органнары, дәүләт бюджеттан тыш фондлар белән идарә итү органнары һәм муниципаль органнар функцияләрен, тиешле территориаль органнар һәм ведомстводагы казна учреждениеләрен дә кертеп, тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләүнең гомуми кагыйдәләре турында» 2014 ел, 13 октябрь, 1047 нче карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормага салу турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, әлеге актларның эчтәлегенә һәм аларны үтәүне тәэмин итүгә таләпләрне раслау хакында» 2016 ел, 20 апрель, 242 нче карары

нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасының дәүләт бюджеттан тыш фондлары белән идарә итү органнары һәм аларның территориаль органнары, ведомстволарындагы казна учреждениеләре (алга таба – оешмалар) функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны (алга таба – эшчәнлекне тәэмин итүгә норматив чыгымнар) билгеләү кагыйдәләрен расларга.

2. Оешмалар әлеге карарның 1 пунктында расланган кагыйдәләр белән билгеләнгән үзләре эшчәнлеген тәэмин итүгә норматив чыгымнарны исәпләү тәртибен кулланырга тиеш дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормага салу турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, әлеге актларның эчтәлегенә һәм аларны үтәүне тәэмин итүгә таләпләрне раслау хакында» 2016 ел, 20 апрель, 242 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 27 март, 186 нчы карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормага салу турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә, әлеге актларның эчтәлегенә һәм аларны үтәүне тәэмин итүгә таләпләрдә:

9 пунктта «һәм бюджет» сүзләрен төшереп калдырырга;

10 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасының дәүләт бюджеттан тыш фондлары белән идарә итү органнары һәм аларның территориаль органнары, ведомстволарындагы казна һәм бюджет учреждениеләре һәм дәүләт унитар предприятиеләр аерым товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алганда аларның функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны исәпләүдә кулланыла торган сатып алучылар тарафыннан сатып алына торган товарлар, эшләр, хезмәтләрнең аерым төрләренә таләпләрне, товарлар, эшләр, хезмәтләр исемлеген, аларның саны нормативларын, куллану үзенчәлекләрен һәм бүтән сыйфатларын билгеләү кагыйдәләрен раслый торган карары түбәндәгеләрне билгеләргә тиеш:».

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин